Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Кече Шыңар торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

02.11.2020 № 3

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел 16нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең Кече Шыңар торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1.2021 нче елда Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге Кече Шыңар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Кече Шыңар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar бастырып чыгарырга.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов